| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>Ул. Советская, д.33, село Кунгер, 422008<br>Тел.: (8-84369) 3-60-38; факс: 3-60-38 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КҮҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>Советская урамы., 33 нче йорт, Күңгәр авылы, 422008<br>Тел.: (8-84369) 3-60-38; факс: 3-60-38 |
| --- | --- | --- |

# КАРАР

**«05 » ноябрь 2019 ел.** **№ 9**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

1. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, “Җирләү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы “Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 нче номерлы “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

2. Әтнә мунципаль районының Күңгәр авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәтләр бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 елнын 1нче ноябреннән гамәлгә кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (http:pravo.tatarstan.ru) веб–адресы буенча, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ruвеб–адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл башкарма
комитеты җитәкчесе: Г.Х.Гарипова

Әтнә муниципаль районы
Күнгәр авыл башкарма комитетынын
2019 елнын 5ноябрендэге 9 номерлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күнгәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3937-43 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 475-51 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1533-53 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл башкарма комитетының
2019 елның 5 ноябрендәге 9 номерлы карарына
2 кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 213-97 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3723-46 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 475-52 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1533-52 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |